
## Буш урын

Уйнаучылар, кулга-кул тотынышып, түгәрәккә тезеләләр. Балалардан берсе әйдәүче булып сайлана, ул, кулына яулык алып, түгәрәкнең тышкы ягына чыга. Калган балалар, түгәрәкләнеп, идәнгә утыралар. Әйдәүче бала түгәрәкнең тышкы ягында йөри һәм берәр баланың җилкәсенә кагыла. Әлеге бала тиз генә урыныннан торып, әйдәүчегә каршы түгәрәк буйлап (уң якка таба) йөгереп китә. Әйдәүче, буш урынны алдан алып калырга теләп, теге баланыә каршысына йөгерә. Бушаган урынга кем беренче килеп җитсә, шул утырып кала, ә урынсыз калган бала әйдәүче була.

***Бергәләп өйрәник***



# ***Исәнме, Яңа ел!***

***Әти-әниләр өчен методик ярдәмлек***

***(6-7 яшь)***

## Табышмаклар

а) Елга ул тик бер килә,

Ул килсә, җир гөр килә.

Яшел чыршы әйләнә

Якты заллар күркенә. (Яңа ел)

б) Кыш бабайның юлдашы,

Аның белән гел бергә.

Шуңа аны җәй көне

Мөмкин түгел күрергә.

Җәй көне ул бөтенләй

Мөмкин хәтта эрергә,

Суга әверелергә. (Кар кызы)

в) Килә бары кыш җиткәч,

Иске ел үтеп киткәч.

Үзе белән һәрвакыт

Яңа ел алып килә.

Бүләк тулы капчыгын

Иңенә салып килә. (Кыш бабай)

## Һай, Кыш бабай

Кемнең кигән киемнәре

Кем соң безгә шундый ямьле

Энҗе кар бөртекләре? Яңа ел алып килә? Кемнең көмеш күк сакалы,

Матур-матур капчыкларга

Чәчләре, керфекләре?

Күчтәнәч салып килә?

Ә дигәнче үсте бабай —

Үзебездән дә биек.

Эчкә сыймый шатлыгыбыз —

Киттек тирәли биеп.

Чаңгы-чанада шуарга

Булды шома тавыбыз.

Кем безгә аны ясаган,

Кем икән ул, табыгыз...

*Җәвад Тәрҗеманов*

## Хәрәкәтле уеннар

### Әйберне сакла!

Балалар, аякларын аерып басып, кулларын артка куйган хәлдә, түгәрәккә тезеләләр. Бер бала түгәрәкнең уртасында тора. Һәр баланың алдында нинди дә булса берәр уенчык ята. Әйдәүче балалар алдындагы уенчыкны алырга тырыша, ә балалар ул килә башлагач чүгәлиләр дә аны куллары белән каплыйлар. Әйдәүче читкә китү белән торып басалар һәм кулларын артка куялар. Уенчыгын алдырган бала түгәрәктән арткарак чигенеп китә (уенчыгын саклап кала алса, кире урынына кайта). 2–3 бала әйберен алдыргач, яңа әйдәүче сайлана. Уен кабатлана.